Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 1**

Масловка авылы 21.01.2026 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 28.04.2023 елның 8 номерлы «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында" 28.11.2025 № 425-ФЗ Федераль законы нигезендә, "Масловска" авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын күздә тотып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 28.04.2023 №8 «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына (17.06.2024 №4, 04.11.2024 №12 редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) физик затның Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә вафат булуы турында игълан ителүе (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артыграк күләмдә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта да, бурыч өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артмаган күләмдә бурыч өлешендә мондый физик зат вафат булганнан соң өч ел узгач һәм салым органында мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүмат булмаганда;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге, Масловка авылы, Централь урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге Башлыгы А.И.Егоров